КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО СОЦИАЛЬНО-
ЭКОНОМИЧЕСКОМУ
МОНИТОРИНГУ
ул. Г.Камала, д. 24 а, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ
МОНИТОРИНГ
КОМИТЕТЫ
Г.Камал ур., 24а йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон/факс (843) 292- 94- 82. E-mail: ks.em@tatar.ru, сайт: http://monitoring.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**10.03.2020** Казан ш. **N 8-ос**

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алуы тәртибе турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законның 17 статьясындгы 1 өлешенең 3 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алуы тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

әлеге боерык белән Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен таныштырырга;

Тәртипне Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының «Коррупциягә каршы сәясәт» стендында урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Комитетының түбәндәге боерыкларының үз көчләрен югалтуын танырга:

«Эшкә яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларга идарә итүдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуына яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенә рөхсәт бирү тәртибе турында» 19.07.2017 № 23-ос;

«Эшкә яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларга идарә итүдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуына яисә аларның коллегиаль идарә

органнарны составына керүенә рөхсәт бирү тәртибенә Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының 19.07.2017 № 23-ос боерыгы белән расланган үзгәрешләр кертү турында» 23.04.2019 № 11-ос.

4. Юридик сектор түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Хөкүмәте Рәсми порталындагы Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты сайтындагы «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә урнаштырырга;

әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис В.П.Кандилов

Татарстан Республикасының
Социаль-икътисадый
мониторинг комитетының
10.03.2020 № 8-ос боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алуы тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре, Комитет) коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алуы процедурасын билгели.

2. Әлеге Тәртип Комитет рәисе (алга таба – рәис) эшкә яллаучы вәкиле (аның вазыйфаларын башкаручы зат) булган граждан хезмәткәрләренә кагыла.

Әлеге Тәртип граждан хезмәткәрләренең сәяси партиягә, һөнәри берлек органына, шул исәптән Комитетның башлангыч һөнәри оешмасының сайлаулы органына идарә итүдә катнашу очракларына, бүтән иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләренң съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу очракларына кагылмый.

3. Граждан хезмәткәренең коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә катнашуы мәнфәгатьләр конфликтына яисә вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр конфликты ихтималына китермәскә тиеш.

4. Коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алуы әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә граждан хезмәткәренең язмача гариза бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Граждан хезмәткәре Комитетның коррупциячел һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затына (алга таба – Җаваплы зат) коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә катнаша башлаганчы ук гариза тапшыра.

6. Җаваплы зат әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча гаризаны кергән көнендә Журналда терки.

7. Теркәлгән көннән биш эш көне эчендә Җаваплы зат гаризаны карый һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны карау барышында Җаваплы зат гариза биргән граждан хезмәткәреннән коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә планлаштырылган катнашу функцияләрен билгеләүче аңлатамаларны һәм документларны соратып алырга хокуклы.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә катнашуга рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдим булырга тиеш.

8. Җаваплы зат гаризаны, бәяләмәне һәм башка материалларны (булса) кушып, коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә катнашуга граждан хезмәткәренә рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен рәис каравына тапшыра.

Рәис Җаваплы заттан гаризаны алган көннән ике эш көне эчендә карар кабул итә.

Карар гаризага тиешле резолюция салу юлы белән рәсмиләштерелә.

9. Җаваплы зат рәис тарафыннан карар кабул ителгән көннән ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә карарны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы мөһире белән таныкланган язманы һәм гаризанның рәис резолюциясе салынган күчермәсен кул куйдырып тапшыра. Гаризаның рәис резолюциясе салынган төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси эш кәгазьләренә кушып куела.

________________________________

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алуы тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты рәисенә

______________________________________

______________________________________
(Ф.Ис.Ат.ис., биләгән вазыйфасы һәм структур бүлекчә

______________________________________
яшәү урынының адресы

______________________________________
телефон номеры)

## Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алуы турында гариза

Миңа ________________________________________________________________
(оештыру-хокукый формасы,

________________________________________________________________
атамасы, ИНН, адресы)

түләүсез нигездә ________________________________________________________________ сыйфатында

________________________________________________________________
(идарәнең бердәнбер башкарма органы яисә коллегиаль органы атамасы)

идарә итүдә катнашырга рөхсәт итүгезне үтенәм.

______________ ____________________ ________________________________________
(датасы) (имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алуы тәртибенә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алуы турындагы гаризаларны теркәү

ЖУРНАЛЫ

| № т/с | Теркәү датасы | Гариза бирүченең Ф.Ис.Ат.ис., вазыйфасы | Гариза бирүченең имзасы | Җаваплы затның Ф.Ис.Ат.ис. | Җаваплы затның имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |